Республика Татарстан
Совет Альметьевского сельского
поселения Сармановского
муниципального района

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Әлмәт авыл җирлеге советы

РЕШЕНИЕ

КАРАР

2018 ел, 10 август

№15

Сарман муниципаль районының «Әлмәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проект буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 31 ст., «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы, «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Әлмәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлегендә Әлмәт авыл җирлегендә 2018 елның 21 июнендәге 10 номерлы карары белән расланган гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмә, Сарман районы прокуратурасының 02-07-01/2018 номерлы протесты нигезендә карар итте:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Әлмәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проект буенча әлеге карарга кушымта нигезендә гавами тыңлаулар билгеләргә.

2. Билгеләргә:

- гавами тыңлауларны оештыручы - Әлмәт авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясе;

- гавами тыңлаулар үткәрү вакыты - 2018 елның 30 августында 14 сәгать;

- үткәрелү урыны - ТР, Әлмәт авылы, Ленин урамы, 56а йорт, Сарман муниципаль районының Әлмәт авыл җирлеге башкарма комитеты;

- Татарстан Республикасы, Әлмәт авылы, Ленин урамы, 56а йорт, Сарман муниципаль районының Әлмәт авыл җирлеге башкарма комитеты (эш көннәрендә 7.00 дән 16.30 сәгатькә кадәр (төшке аш тәнәфес 11.30 дан 13.00 сәгатькә кадәр) язма тәкъдимнәр һәм кисәтүләр кертелергә мөмкин булган адрес.

4. Әлмәт авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләре проектын әзерләү комиссияләре:

- Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Әлмәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турындагы проект буенча гамәлдәге законнар нигезендә һәм әлеге карар белән билгеләнгән срокларда гавами тыңлаулар әзерләргә һәм уздырырга;

- гавами тыңлаулар уздыру нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләргә һәм аны билгеләнгән тәртиптә 2018 елның 30 августыннан да иртәрәк булмаган срокта бастырып чыгарырга;

- Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Әлмәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Сарман муниципаль районының рәсми сайтында веб-адрес буенча урнаштырырга: http://sarmanovo.tatarstan.ru/.

5. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы» http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча һәм Сарман муниципаль районының рәсми сайтында http/ sarmanovo.tatarstan.ru. веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Әлмәт авыл җирлеге
Советы Рәисе Д.Ә. Газизов